**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**ЛАИШЕВСКИЙ**
**МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН**
**СОВЕТ ГОРОДА ЛАИШЕВО**

422610 г.Лаишево,
ул. Коммунальная, д.3
тел: 8-(84378) -2-50-62
факс: 8-(84378) -2-50-62

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ЛАЕШ**
**МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**ЛАЕШ ШӘҺӘР СОВЕТЫ**

422610 Лаеш ш.,
Коммунальная ур., 3 нче йорт
тел: 8-(84378) -2-50-62
факс: 8-(84378) -2-50-62

---

**2021 елның 9 июне** **4 номер**

# КАРАР

**«Лаеш шәһәре» муниципаль берәмлегенең**
**2013елның 10 октябрендәге 56 номерлы**
**җирдән файдалану һәм төзелеш Кагыйдәләренә**
**үзгәрешләр кертү турында**

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 33 статьясы, «Россия Федерациясе җирле үзидарәсен оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Лаеш шәһәре» муниципаль берәмлеге уставы нигезендә, «Лаеш шәһәре» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү проекты буенча ачык тыңлаулар беркетмәсен һәм бәяләмәне карап, Лаеш шәһәре Советы КАРАР ИТТЕ:

1. «Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Лаеш шәһәре» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә(үзгәрешләр кертү турында)» 2012 елның 10 октябрендәге 56 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Лаеш шәһәре» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелешләр кагыйдәләренә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- «Шәхси торак төзелеше», «шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару өчен», «туктатылган төзелеш өчен» рөхсәт ителгән җир кишәрлекләренең минималь күләмен - 1000 кв. м. дип билгеләргә.
- «Шәхси торак төзелеше», «шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару өчен», «туктатылган төзелеш өчен» рөхсәт ителгән җир кишәрлекләренең максималь күләмен -2500 кв. м. дип билгеләргә.

2. . Әлеге карарны “Кама ягы”(«Камская новь») район газетасында, Интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб–адресы буенча һәм интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре Порталында урнаштырылган Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының рәсми сайтында- http://laishevo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан н(халыкка җиткерелгән) көненнә үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Лаеш шәһәре Советының җирдән файдалану, экологик иминлек һәм төзекләндерү мәсьәләләре буенча комиссиясенә йөкләргә.

**Башлык-Татарстан Республикасы**
**Лаеш муниципаль районы Лаеш шәһәре**
**Советы рәисе** **И.Ф.Зарипов**